Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFƟNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 13 (13)

29 декабрь 2011 ел

### *Хөрмәтле коллегалар, дуслар!*

*Казан федераль университетының барлык укытучыларын, хезмәткәрләрне, студентлар һәм аспирантларны чын күңелдән Яңа ел белән котлыйм! Бу бәйрәм җылылык һәм сафлык белән тулган. Ул һәр кеше күңелендә яңа үзгәрешләргә, игелекле эшләргә һәм үсешкә өмет уята. Казан федераль университеты коллективы халыкның иң яраткан бәйрәмен оптимистик рухта, бердәм булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте кабул иткән Үсеш программасын уңышлы рәвештә тормышка ашырып каршы ала. Киләсе елда да планнарны тормышка ашыру өчен килешенгән уртак эшебез фән-мәгарифебезне үстерүдә, инновацион икътисадны формалаштыруда үз өлешен кертер дип ышанам.*

*Сезгә Яңа елда зур җиңүләр, нык сәламәтлек һәм имин тормыш, барлык планнарыгызның тормышка ашуын телим!*

*Яңа 2012 ел көндәлек яшәү рәвешен үзгәртсен иде. Бер-беребезне ихлас күңелдән аңлап яшәсәк, университетыбыз яңа үсешкә ирешер дип уйлыйм.*

***И.Р.Гафуров,***
***КФУ ректоры***






Энже Ибраһимова фотосы

# Яңа ел килә!

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Елның соңгы көннәрендә Казан федераль университетында да, һәр җирдәге кебек, чыршы бәйрәмнәре үтә. 26 декабрь көнне – Филология һәм сәнгать институтында «Чыршы-party», 27 декабрьдә шул ук институт һәм Педагогика һәм психология институты хезмәткәрләренең балалары бәйрәм итте. КФУның «Мизгел» яшьләр театры да зур бәйрәм ясады.

Бу сихри бәйрәм бөтен кешене үз тылсымы эченә алып кереп китә дә хыял канатларында очырта. Сабый баладан алып, өлкән яшьтәге кешеләргә кадәр әлеге бәйрәмне көтә, бүләкләр әзерли, чыршы бизи... Үткән елга нәтиҗәләр ясап, киләчәккә планнар корып, күңелле рухта тәмамлыйлар елны.

Миңа бәйрәмнәрнең өчесендә дә булырга туры килде. Берсендә – гади тамашачы, икенчесендә – редакция вәкиле, өченчесендә оештыручы буларак катнаштым.

«Чыршы-party» яңача бизәлгән зал, зур чыршы, сихри музыка белән үзенә җәлеп итте. Чарада институт директоры Рәдиф Җамалетдинов, фәнни эшләр буенча директор урынбасары Искәндәр Ярмәкәев, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Рамил Мирзаһитов, социаль һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Рөстәм Камалов катнашты. Концерт югары рухта үтте. Вальс, һинд биюләре, укытучыбыз Эльвира Закированың үз студентлары белән сәхнәгә менеп җырлавы бар тамашачыны сокландырды. Һәр катнашучының чыршы бизәүгә өлеш кертүе бәйрәмгә тагын бер ямь өстәде. Тик рус, татар телләрендә номерларның аз булуы гына бераз күңелне тырмап калды.

Ике институт хезмәткәрләренең балалары өчен оештырылган кичә көне буе дәвам итте. Көннең беренче яртысында – мәктәпкәчә яшьтәге балалар, икенче яртысында исә мәктәп укучылары өчен бәйрәм гөрләде.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • Ике авыз сүз

28 декабрь көнне Казан федераль университетының Геология музеенда «Шифалы минераллар» исемле уникаль күргәзмә ачылды. Экспозициядә бөтен Җир шары буенча 2000нән артык минерал тәкъдим ителә. Аларның һәркайсы йөрәккан тамыры, онкологик, буын, тире авыруларыннан дәвалау сыйфатына ия. Шулай ук ташларның сезнең энергетикага ничек тәэсир итүен, йолдызлыгыгызга туры килү-килмәвен дә белергә мөмкин. Шифалы минералларны, ташларны сувенир рәвешендә да алырга була.

• • • •

27 декабрь көнне ТРның Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгында өстәл теннисы буенча Татарстан остарларын тәбрикләү тантанасы узды. Алар Европа Беренчелегендә (Казан), студентлар арасында Европа Чемпионаты (Мадейра, Португалия), яшьләр арасында Россия Беренчелеге (Санкт-Петербург) һ.б. масштаблы ярышларда зур уңышларга ирештеләр. «2011 елның иң яхшы спортчысы» номинациясендә КФУның юридик факультеты студенты Ольга Власова җиңүгә лаек булды. Аның бу ел дәвамында ирешкән уңышлары: Студентлар спорты III Бөтенроссия фестивалендә шәхси разрядта 1 урын һәм яшьләр арасында Россия Беренчелегендә шәхси зачетта 3 урын, студентлар арасында Европа Чемпионатында парлы разрядта шулай ук 1 урын. Моннан тыш, КФУның тагын ике студенты: студентлар арасында узган Европа Чемпионатында Ольга Власованың иптәше Эльза Шәрипова һәм шул ук турнирда бронза медаль иясе Полина Михайлова мактауга лаек булды.

• • • •

4 гыйнвар көнне А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтының Бутлеров аудиториясендә Фармацевтиканың фәнни-мәгариф үзәге дисциплинарара семинары уза. Чараның программасы түбәндәгедән гыйбарәт: «Казан университетында геннар һәм күзәнәкләрне өйрәнү технологияләре» (докладчы – биология фәннәре докторы, доцент Альберт Ризванов) һәм «Биомедицинада ген-күзәнәк технологияләрен куллану перспективалары» (докладчы – биология фәннәре докторы, профессор Сергей Киселев) темаларына чыгышлар ясалачак. Биредә барлык теләүчеләр дә катнаша ала.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

## • Универсиаданы якынайтып

# «Сәламәт бул!»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Кичә КФУ тарихы музеенда профессор-укытучылар составы һәм хезмәткәрләр катнашында оештырылган Спартакиаданың җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Ул 23 октябрьдә старт алган иде.



Радифа Шәфыйкова фотосы

Ел дәвамында узган спорт чараларын саный башласаң... Дөрестән дә, узып баручы ел тагын шушы үзенчәлеге белән истә калачак, чөнки уку йортыбызда сәламәт яшәү рәвешенә багышланган чаралар бик күп узды һәм зур җиңүләр алып килде.

Хөрмәтле укытучыларыбыз да читтә калмады, физик яктан булмаса, рухи яктан көч биреп тордылар.

**Ахыры 2нче биттә.**

● Универсиаданы якынайтып

# «Сәламәт бул!»

**Башы 1нче биттә.**

Ләкин спортка мәхәббәтне аның белән дус кеше генә тәрбияли ала. Шул максаттан чыгып, быел киң масштаблы төрле спорт төрләрен колачлаган Спартакиада уздырылды. Аның девизы да – «Сәламәт бул!» Максаты, беренче чиратта, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау. Әлбәттә инде, сәламәтлекне ныгыту, спорт традицияләрен торгызу һәм саклау, профессор-укытучыларны, хезмәткәрләрне физик тәрбия белән даими рәвештә шөгыльләнүгә мәхәббәт уятуга басым ясала.

«Спартакиадада 20 бүлектән 500 дән артык кеше катнашты. Традицион спорт төрләре белән бергә яңаларны да кертеп җибәрдек. Бию – шундыйлардан. Катнашмыйча калган факультетлар алдагы елларда калганнардан үрнәк алырлар дип уйлыйм», – диде социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор Ариф Межведилов.

9 номинация буенча җиңүчеләрне уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов котлады һәм алга таба да зур уңышлар теләде.

*Шахмат:*
III урын – Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты.
II урын – Физика институты.
I урын – Юридик факультет.

*Өстәл теннисы:*
III урын – Математика һәм механика институты.
II урын – Студентлар шәһәрчеге коллективы.
I урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.

*Волейбол:*
III урын – КФУнын Алабуга филиалы.
II урын – «Бустан» спорткомплексы коллективы.
I урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.

*Йөзү:*
III урын – Юридик факультет.
II урын – КФУнын Алабуга филиалы.
I урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.

*Бию:*
III урын – Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты.
II урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.
I урын – Филология һәм сәнгать институты.

*Мини-футбол:*
III урын – Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты.
II урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.
I урын – Идарә итү аппараты.

*Баскетбол:*
III урын – Юридик факультет.
II урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.
I урын – Биология һәм туфракны өйрәнү факультеты.

*Бильярд:*
III урын – КФУнын Алабуга филиалы.
II урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.
I урын – Идарә итү аппараты.

*«Күнелле стартлар»:*
III урын – Студентлар шәһәрчеге коллективы.
II урын – Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге идарәсе.
I урын – Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты.

● Фән дөньясында

# Арбузов бүләкләре

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

27 декабрь көнне КФУның Бутлеров аудиториясендә органик һәм элементоорганик химия өлкәсендәге уңышлары өчен яшь галимнәргә Арбузов премиясен тапшыру тантанасы узды.



Алия Галимуллина фотосы

■ *Рәсемдә (сулдан уңга): Д.Татаринов, Д.Фәткуллина һәм Алексей Салин*

Совет химигы, СССР Фәннәр Академиясе академигы, Социалистик Хезмәт Герое Александр Арбузов исеме безгә яхшы таныш. Ул 1900 елда Казан университетын тәмамлый. 1911-1930 елларда биредә профессор булып эшли. Александр Арбузов химия өлкәсендә төрле кислоталар, алар арасында барган бәйләнешләр турында зур ачышлар ясый.

Фәнгә тагын бер Арбузов – Александр Арбузовның улы Борис килә. Ул Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институтын тәмамлый. Әтисе юлын дәвам итеп, 1935-1938 елларда Казан химия-технология институтында профессор булып эшли. Шулай ук СССР Фәннәр Академиясе академигы 1938 елдан гомерен Казан университетына багышлый. Казан университеты каршындагы А.М.Бутлеров исемендәге Химия фәнни-тикшеренү институтының директоры була. Әтисеннән аермалы буларак, Борис Александрович органик һәм физик химия өлкәсендә эшли.

Әлеге ике зур галимнең исемен мәңгеләштерү, яшь буында фәнни-тикшеренү эшләренә кызыксыну уяту, яңа проектларны тормышка ашыруда матди ярдәм күрсәтү максатыннан, Арбузов премиясе булдырыла. Конкурсны һәр ел саен Казан шәһәре Башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре комитеты Казан федераль университеты, А.Е.Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты белән берлектә уздыра. Ул быел җиденче тапкыр тапшырылды. «Дөнья күләмендә Арбузов исемендәге Халыкара премия 2 елга бер мәртәбә бирелә. Россия күләмендә әлеге мактаулы исемгә ике генә галим лаек. Татарстанда да элементоорганик химия өлкәсендәге уңышлары өчен яшь галимнәргә тапшырыла торган Арбузов премиясе дәрәҗәсе бик зур һәм ул алга таба тагын да үсәргә стимул бирә», – диде А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты директоры, ТР Фәннәр Академиясе мөхбир-әгъзасы Владимир Галкин.

Яңа казанышлары өчен Казан федераль университеты галиме Алексей Салин, А.Е.Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институтыннан Дмитрий Татаринов беренче дәрәҗәдәге премиягә (25 мең сум) лаек булды. Өченче дәрәҗәдәге премия (15 мең сум) Казан милли тикшеренү технология университетыннан Дания Фәткуллинага бирелде. Бәяләүчеләр икенче урын бирмәүне кирәк тапты. Конкурста катнашкан башка финалистларга да Мактау кәгазьләре һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды. Бүләкләү тантанасы тәмамланганнан соң, җиңүчеләр үзләре ясаган ачышлар турында кыскача гына презентация тәкъдим итте.

Чарага килгән кунаклар арасында конкурсның беренче җиңүчеләре дә, инде фән дигән зур дәрьяда үз урыннарын тапкан хөрмәтле галимнәребез дә, гади студентлар да бар иде. Аларның һәркайсына Яңа ел яңа җиңүләр алып килсен.

● Яңа ачыш

# Медицинада - мәгълүмати технологияләр

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

28 декабрь көнне КФУның мәгълүмати технологияләр үзәгендә «Медицинада мәгълүмати технологияләр» дип аталган лаборатория ачылды. Тантаналы ачылышны лабораториянең җитәкчесе Руслан Гайсин башлап җибәрде.

Ул кыскача гына лаботаториядә нинди юнәлештә эш алып баралачаклары турында сөйләде. Бу юнәлешләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:
- сәламәтлек саклау үзәкләрендә идарәкомпьютертехнологияләре белән эффектив, югары дәрәҗәдә идарә итәргә өйрәтү;
- иммуночиплардан дөрес файдалану;
- спортта иммитацион модельләштерү;
- вак детальләрне 3-d форматта карауга ирешү (күзәнәкләр, кан йөреше, томографиядә) һәм башка бик күп әһәмиятле тармакларны үзләштерергә өйрәтү.

Руслан Ренат улы әйтеп үткәнчә, лабораториядә КФУда укучы барлык студентлар да белем алырга мөмкин. Бары тик математик анализ, алгебра өлкәсендәге белемнәр бик югары дәрәҗәдә булырга тиеш. Тагын шунысын өстәп әйтергә кирәк: лаборатория КИР (корпоратив мәгълүмати чаралар) компаниясе белән хезмәттәшлек итәчәк. Ә бу исә бөтен Россиядә танылган иң яхшы медицина системаларының берсе. КИРдан килеп укытачак белгечләр дә югары квалификацияле, алар студентларны мөмкин кадәр күбрәк материал белән таныштырырга омтылачаклар. Аеруча да тырыш студентларны үзләренең компанияләренә эшкә алачакларын әйтеп уздылар. Чөнки бүгенге көндә медицина өлкәсендә кадрлар белән эшләү, медицина белешмәләрен исәпкә алу, архивларда мәгълүматларны саклый белү, югалган материалларны тиз генә табу кебек җаваплы эшләрне башкарырдай белгечләр җитешми. Медицина өлкәсендә тоткарлыклар булмасын өчен, ә студентларга тагын да югарырак мөмкинлекләр ачу максатыннан, «Медицинада мәгълүмати технологияләр» лабораториясе үз эшен җаваплы һәм тиешле дәрәҗәдә башкарыр, дигән теләктә Руслан Гайсин лаборатория ишекләрен кызыл тасманы кисеп, ачып җибәрде. Тантанадан килгән кунаклар һәм студентлар зур кызыксыну белән таралышты.



Алия Галимуллина фотосы

● Милләттәшләр

# Пәхләвәле Әстерхан якларында...

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

КФУның Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен камилләштерү һәм яңадан әзерләү үзәгеннән бер төркем укытучылар декабрь аенда Әстерхан якларында татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен үткәрелгән семинарда булып кайттылар.



Бу чара Розалия Нигъмәтуллина авторлыгында эшләнгән «Татарча да яхшы бел» укыту-методик комплексына һәм яңа Федераль стандартларга нигезләнеп уздырылды. Ана теле укытучылары Татарстаннан килгән кунакларны бик җылы кабул итте.

Очрашуда РФ Дәүләт Думасы депутаты, «Дуслык» җәмгыяте җитәкчесе Әнвәр Алмаев, «Идел» татар газетасының баш мөхәррире Нәфисә Хәмидуллина да катнашты. Мөгаллимнәр татар халкы яши торган авылларга да сәяхәт кылды. Ярлы Түбә авылы мәктәбенең башлангыч сыйныфларында татар теле укытучы һәм балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче Вәлидә Суфиева әзерләгән телне йотарлык пәхләвә белән чын татарча итеп ясалган чәй дә, Киләче авылының зур мәчете, яшьләрнең дингә кайтуы һәм туган җирләрендә төпләнеп калуы, бай-мул тормышта яшәүләре – барысы да, халкыбызның кайда да һәм беркайчан да югалмаячагы турында сөйли.

● Яңа елны каршылап

# Аждаһадан ни көтәргә?



*Сәгать телләре төнге 12 не сукканда, йомшак Куян елы урынына кара, су Аждаһасы киләчәк. Көнчыгыш календаре буенча ул әле 2012 елның 23 гыйнварыннан гына хакимлек итә башлаячак. Кемнәрдер бу ел килүдән бераз куркып та кала, ә кемнәрдер аны зур ышаныч белән көтә. Астрологлар фикеренчә, бер билгедә ике стихиянең урын алуы ел дәвамына сынауларның күп булачагын күрсәтә. Кемгәдер утны да, суны да кичәргә туры киләчәк. Дөнья бетү турындагы хорафатларны юкка чыгарырга, онытырга кирәк булачак. Аждаһа андый юк-бар сүзләрне яратмый. Яңа ел хуҗасы спорт һәм табигатькә яхшы мөнәсәбәттә булган кешеләрне, төрле маҗараларны үз итә. «Оптимистларга һәркайда да уңыш елмаячак, ә пессимистлар үзләренә үпкәләсеннәр», – ди астролог-галимнәр.*

# Һәр илнең үз гадәте!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче



Яңа ел бәйрәме җир йөзенең теләсә-кайсы почмагында иң көтелгән бәйрәмнәрнең берседер, мөгаен. Шулай да бәйрәм үткәрүнең тәртипләре бер-берсеннән шактый аерылып, үзенчәлекле төсмер ала. Һәр төбәкнең үз гореф-гадәтләре һәм йолалары бар.

Мәсәлән, ***Италиядә*** Яңа ел көнне кешеләр иске әйберләрдән арынырга тырышалар. Ә Яңа ел үзе 6 гыйнварда гына башлана. Өстәл түренә италиялеләр, беренче чиратта, чикләвек, виноград куялар. Болай эшләү озын гомерле, саусәламәт булу, гаиләдә иминлек саклау символы икән.



***Эквадорда*** Яңа ел төнендә курчаклар яндыру йоласы бар. Бу исә тол хатыннарның азрак булуын символлаштыручы билге. Тагын шунысы кызыклы: әлеге ил халкы, курантлар сукканда, өй тирәләрен чемодан белән 12 тапкыр әйләнеп чыгарга тырышалар икән. Әгәр шулай эшләсәң, елың сәяхәтләргә бай булыр, ди. Ә инде яңа елда үз мәхәббәтләрен табарга теләүчеләрнең өсләрендә сары төстәге кием булырга тиеш.

***Швециядә*** исә, яңа елга керер алдыннан, йортларда барлык утларны сүндерәләр, бары тик урамдагы гирлянда-лампалар янып торырга тиеш.

***Көньяк Африка Республикасында*** тагын да сәеррәк гадәт бар: бу илнең халкы, Яңа ел җиткәч, тәрәзәләрдән иске суыткычларын тотып ата икән. Шул сәбәпле, урамда транспорт йөрүдән туктый һәм тынычлык урнаша.

***Англия*** – Яңа елны әкияти рухта, шау-шу белән каршылый торган илләрнең берсе. Карнавал костюмнарын Англиядә инде ел башында ук әзерләп куялар. Биредә сәгать 12 дә курантлар түгел, ә чаң сугалар. Ел дәвамында бәхетле, тыныч, тату яшәргә теләүчеләр, чаң сукканда, кулга-кул тотынышып торалар һәм, әлбәттә, бер-берсенә бүләкләр бирәләр.



***Колумбиядә*** Яңа ел күбрәк балаларның күңел ачуы төсмерен ала. Чөнки һәрбер гаилә диярлек өйләренә аларның Кыш бабае – Папа Паскуалены чакыра. Ә ул исә балаларны уен-көлке, бүләкләр белән шатландыра.

***Финляндия*** Кыш бабайның чып-чын туган иле дип санала. Бәйрәм төнендә күрәзәлек итү гадәте киң таралган.

***Ирландиядә*** Яңа ел дини бәйрәм буларак уздырыла. Монда ул башка күп илләрдәге кебек үк Раштуа дип атала. Тавыш, ыгызыгы бу ил өчен ят нәрсә. Яңа ел төнен гаилә белән бергәләп тыныч кына уздырып җибәрәләр.



***Венгриядә*** Яңа ел төнендә сыбызгылардан һәм һәртөрле тавыш чыгара торган уенчыклардан файдаланалар. Бу традиция аларда элек-электән килә һәм аның асылы өйне начар рухлардан, бозыклыклардан арындыру булып тора.

Күп кенә ***төрки һәм Көнчыгыш халыкларының*** тамашаларга бай, сюжетлы уеннарны үз эченә сыйдырган уртак бәйрәме Нәүрүз яңа елны каршылау бәйрәме буларак элеккеге заманнардан ук уздырыла. Ул Көнчыгыш календаре буенча 21 мартта, ягъни көн белән төн тигезләшкәч үткәрелә. Мәгълүм булганча, XVIII гасырга хәтле ***татар халкы*** Яңа елны март аеның егерме берендә каршы алган. Бу көн Иран календаре нигезендә «Нәүрүз» дип аталган. «Нәүрүз» сүзе фарсы теленнән кергән, «яңа көн» дигәнне аңлата. Бүгенге көндә Төркия, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Казакъстан кебек илләрдә Нәүрүз рәсмиләшкән дәүләткүләм бәйрәм буларак уза. Кайбер төрки халыкларда бәйрәмнең беренче көнендә бөтен кеше дә өйдә булырга тиеш, Нәүрүзнең беренче көнендә өйдә булмасаң, җиде ел өеңне күрмәссең, дигән ышану бар.

Гореф-гадәтләрнең никадәр төрле булуына карамастан, Яңа ел төнендә барлык илләрдә дә һәркем теләкләр тели, иске елда чынга ашмаган хыялларының кабул булачагына өметләнә. Һәркемдә бәйрәмчә күтәренке кәеф, бизәлгән өйләр, бүләкләр... Һәм иң мөһиме: барчабыз да бу бәйрәмне иң якын кешеләребез янәшәсендә үткәрергә омтыла!

# Кем белән каршыларга?

*Яңа ел алдыннан көннәр җылытып, түбәләрдән боз-сөңгеләр сузылып төшә. Бала чактагыдай кызыктырып торалар бит әле җитмәсә! Кеше күрмәгәндә, бәреп төшерәсе килә. Бер дәртләнеп киткәч, кешедән дә тартынмыйсың кайчак. Рәхәт мизгелләр... Уйлап-уйлап куям да бер генә бәйрәмне дә Яңа елны искә алган кадәр хәтергә төшермибез икән бит! 8 мартын да, 23 февралең дә, хәтта узган елгы туган көн дә онытыла... Ә Яңа ел – юк! Һәр елы үзенчәлекле, хатирәләргә бай була бит аның. Үземнән генә чыгып та әйтә алам: бәйрәмне үткәрү истәлекләре һәр елны үзенә күрә бер төрле булалар. Инде аны каршылау планнарын да бер-ике ай алдан кора башлыйбыз... Яшьтәшләремнән дә күбесе бармак бөгә-бөгә ул көнне көтә. Әйе, яшь чакта бит ул аеруча да романтик рухта үткәрелә торган бәйрәмнәрнең берсе. Ә инде олыгайган саен, Яңа ел гаилә бәйрәменә әйләнә бара. Кызык өчен генә булса да төрле яшьтәге берничә кешедән Яңа ел төнен кайда каршыларга теләүләрен сорадым.*

*Мәсәлән, **15-17 яшь** аралыгындагы яшүсмерләрнең бар теләкләре – дуслар, иптәшләр янында утыру. Алар өчен гаиләдән читтәрәк кенә булсын бәйрәм кызыклары...*

*Ә инде **18-21 яшьлек** сораштырганнарымның күпчелеге сөйгәннәре белән булуны кулай күрә. Алар өчен романтика беренче урында. Ә нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килә, дигән соравыма 85% ка якыны бүләк алырга кирәк, дип җавап бирде.*

*Яшь барган саен, акыл керә, дигән гыйбарә дөрестерме, әллә хәзерге яшьләр тиз олыгаялармы, белмим, әмма **22-27 яшьлек** танышларымның күпчелеге Яңа елны әтиәниләре янәшәсендә уздырырга ниятлиләр. Алар өчен туганнар җылылыгы һәртөрле «тавышлы» компанияләрдән өстенрәк икән.*

*Инде **30 дан өстәрәк** булган сораштыручыларым барысы да Яңа елны гаилә бәйрәме дип билгеләп үтте! Туганнар, якыннар белән җыелышудан да рәхәт нәрсә юк, диләр алар!*

*Әйе, дуслар, һәр чорның үз кызыксынулары, үз үзенчәлекләре бар! Яңа елны кайда каршылау түгел, ә кемнәр белән каршылавың иң мөһимедер, миңа калса! Шуңа да бәйрәмне якыннарыгыз янәшәсендә каршы алыгыз! Аларның уңай энергиясе, истәлекләр ел буена җитәрлек булсын! Яңа елда Яңа куанычлар, Яңа танышлар, Яңа бәхетләр телибез Сезгә!*

# Яңа ел килә!

**Башы 1нче биттә.**

Төрле-төрле битлекләр кигән балалар чыршы тирәли җырлап, биеп күңел ачтылар. Студентлар тәзегән сценарийның да актив катнашучылары иде алар. Үзләре әзерләп килгән шигырь, җырлары өчен Кыш бабай бүләкләр дә тапшырды. Кайберләре чыршыны гына ялгыз калдырырга ашыкмады.

«Мизгел» яшьләр театры артистлары да күңелле ял итә белә. Бирегә театрның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге җыелды. Моннан 5-10 еллар элек спектакльләрдә уйнаган студентларны инде гаиләләре, балалары белән күрергә мөмкин иде. Кыш бабай (театрның җитәкчесе Марсель Җаббаров) һәм аның учагын сүндерми саклаучы Кар кызы (Ләйсән Шәяхмәтова) кунаклар өчен искиткеч бал-маскарад оештырды. Түгәрәк өстәл янында кызыклы истәлекләр, изге теләкләр, матур җырлар күп яңгырады. Чыршы тирәсендә җырлап-биеп әйләнүдән, үз һөнәреңне күрсәтүдән кечкенәләр генә түгел, өлкәннәр дә читтә калмады. «Шулай бергә җыйналу – минем өчен чиксез бәхет. Еллар үтеп, барыгызның да монда килүе, шатлыкларны, ирешелгән уңышларны минем белән уртаклашуыгыз – хезмәтемнең эзсез калмавына ачык мисал. Укытучы кешегә моннан да зур бәхет була алмыйдыр», – диде театрның җитәкчесе Марсель Җаббаров.

Университетыбызда тырышып уку гына түгел, ә яхшылап ял итә һәм елга нәтиҗә дә ясый беләләр икән дип сокланып утырдым. Киләсе Яңа ел уку йортыма чиксез шатлык-куаныч, уңышлар гына алып килсен!



■ Рәсемдә «Мизгел театры артистлары

## Илһам канатында

**Алнур Камалова** 1993 елның 21 мартында Аксубай районы Иске Кыязлы авылында туган. Биредә урта мәктәпне тәмамлагач, 2011 елда КФУның тәрҗемә белеме һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенә укырга керә. Алнур безгә мәктәп елларыннан ук таныш. Бөтенроссия «Илһамлы каләм» әдәби әсәрләр конкурсында даими катнашып, призлы урыннар алып килде ул. Ә узган ел Гран-прига лаек булды. Сезгә яшь шагыйрәнең яна шигырьләрен тәкъдим итәбез.



### Кайсы яктан дисезме?

*Кайсы яктан бу, дип сорыйсыздыр,*
*Аксубайдан, ап-ак төбәктән.*
*Туфаннардан өзелеп калган җырны*
*Җырлап ятыш ярсу йөрәктән.*

*Кайсы яктан бу, дип сорыйсыздыр,*
*Думавины биргән яктан мин,*
*Киек каз юлыннан күккә ашкан*
*Газиз Үзилегә якташ мин.*

*Кайсы яктан бу, дип сорыйсыздыр,*
*Розалар үскән яктан мин.*
*Нәбирәләр, Хөсәеннәр... исемен*
*Хәтеремә тезәм яттан мин.*

*Кайсы туфрак кыйпылчыгы соң бу?*
*Адашкандыр җилдә, дисезме?!*
*Таң суына манып, туган ягым*
*Көйле иткән мин бу көйсезне.*

*...Кайсы яктан бу, дип сорамагыз!*
*Таныш икән ласа күптән без...*
*Шундый уллар, шундый кызлар булып*
*Иңдерелгән икән күктән без.*

### Көзге бизәкләр

*Болыннарның төсе качкан,*
*Уйнакламый мут колын.*
*Оя-оя йорт казлары*
*Суза хушлашу көен.*

*Ак карлыган куагында*
*Сандугачның оясы*
*Бушап калган ташлаганга*
*Сайраучысы, хуҗасы.*

*Сузылып яткан әнә җирем,*
*Сызылып яткан, ял сорый.*
*Йокымсыравын көчәйтә*
*Торналар, торыйк-торыйк.*


*Кулчатырым җыелып тормый,*
*Яңгыр бүлешә серем.*
*Елак көздәй күз яшьләре*
*Сыга җаннарның керен.*

*Төсле яфрак-кырамадан*
*Түшәлгән чуар сырма.*
*Күз ашыкмый, хозурында*
*Битараф булып торма...*

*Һәр фасылның үз җыры бар,*
*Һәр фасылның – үз төсе.*
*Һәр фасылның сихри көче*
*Кузгата күңелем хисен.*

*Шигъри җанлы йөрәгемә*
*Якын җирнең һәр төсе...*
*Бәрхет япкан кашкарыйдан*
*Инде аңкый көз исе.*

## Дөнья үзебезнеке



# Чын мәхәббәт

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

*(Дәвамы.*
*Башы 10-12 нче саннарда)*

*Танылган немец композиторының бабасы Мозес Мендельсон бер дә матур кеше булмаган. Кыска буйлы булуы өстенә, гарип-көлкеле бөкресе аны тагын да ямьсез күрсәткән.*

*Бервакыт ул бик чибәр Фрумтье исемле кызы булган бер Гамбург сәүдәгәренә кунакка бара. Мозес кызга өметсез гашыйк була. Билгеле, аның ямьсез кыяфәте Фрумтьега бер дә ошамый. Китәр вакыт җиткәч, Мозес, бар батырлыгын җыеп, яраткан кешесе белән соңгы мәртәбә сөйләшергә мөмкинлек булудан файдаланып, бүлмәсенә күтәрелә. Фәрештәдәй чибәр, тик берничек тә егеткә күтәрелеп карамаска тырышуы белән кыз аның җанын телгәли. Берничә мәртәбә сөйләшеп карауны кире какканнан соң, Мозес кыенсынып кына:*

*– Әйтегезче, Сез никахларның күктә башкарылганын беләсезме? – дип сорый.*

*– Әйе, – ди кыз, әлегәчә күзен идәннән алмыйча. – Ә сез?*

*– Мин дә ышанам, – дип җавап кайтара Мозес. Беләсезме, бу дөньяга малай кеше туганда, Аллаһы Тәгалә һәрвакыт күктә аңа кайсы кызга өйләнәчәген билгеләп куя. Мин тугач, Аллаһы Тәгалә миңа да булачак кәләшемне күрсәтте һәм шулвакыт өстәп әйтеп куйды: «Синең хатының бөкре булачак». Мин кычкырып: «Юк, Аллам! Бөкре хатын – ул бик зур трагедия! Үтенеп сорыйм синнән: бөкрене миңа бир, ә ул иң гүзәл хатын булсын!» – дидем.*

*Шунда Фрумтье беренче мәртәбә аның күзләренә күтәрелеп карый, җанының кайдадыр иң тирән җирендә тонык кына истәлекләр селкенеп куйгандай тоела... Ул кулларын Мендельсонга суза, ә соңрак Фрумтье аның гомерлек яраткан һәм ышанычлы хатыны була.*

***(дәвамы бар)***

*(Дж. Кэнфилд һәм М.В.Хансен хезмәтләре файдаланылды).*

## Тәңгә – мунча, җанга – юк

**Ленар ХАММАТОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

# Эшли беләсеңме?..

Менә бит, безнең илгә дә йөз елдан соң (Европаның башка әйдәп баручы илләре белән чагыштырганда) постиндустрия дигән нәмәстәкәй килде. Чәк-чәкләр, баллар, ипи-тоз белән каршы алырга чыккан әбиләр инде әллә кайчан ziratta, билгеле. Ишек шакыгач, кертми булдыра алмадык. Уң аягың белән кер, тазалык-саулык кына алып кил инде безгә...

Беркөнне мәгълүмати технологияләр дәресенә укытучы ике пульт алып керде дә түшәмгә беркетелгән бер проекторны кабыза башлады. Башта беренче пульттагы булган бар төймәгә басып чыкты, аннары икенчесендәгегә... Имеш, хәзер шундый заман, тактага акбур белән язып ятасы юк, шушы әйбер бөтен нәрсәне алыштыра икән, кайбер очракларда укытучының үзен дә...

Кабыза алмаганын күреп, булышырга дус малай төшеп китте. Төймәләр күп – баскала гына! Икесенә берьюлы да, аерым гына да баскалап карады – кабынмады. Ну, технология булса, технология бу, малай! Проекторның үзендә миллион төймә, ике пульт...

Ахырда, кабынмагач, әле бу «кунак» килгәнче булган кабызгычка күз төште. Шуңа басуыбыз булды... Укытучы апа рәхәтләнеп дәресен башлап җибәрде.

Яңа димәктән, кем әйтмешли, кәвешләрне түфлиләргә алыштырыр вакыт хәзер. Һәм шунысы кызык: ул әйберләр, юктан да үзенә җәлеп итеп, безнең тормышны «матурайтып, тулыландырып» торалар. Беркөнне берәүнең телефоны шалтырагач, янымда басып торган абый телефонын кесәсеннән текәләрчә генә чыгарды да, аныкы түгел икәнен аңлап, кире тыгып куйды. «Синең телефон моделе икенче бит, анда мондый көй юк», – дигәнгә ул: «Мин анысын кайдан белим инде? Кемнеке шалтыраса да, үземнекен алып карыйм», – дип җавап кайтарды...

Хәзер бөтен кеше дә тырышып-тырышып «әмрикәләләр»нең телен өйрәнә. Казан урамнарын «WC» хәрефләре басып бетергәч, кая барасың: тел белмичә, керергә теләгән җиреңне бутап, адашсаң, оят үзенең ишекләрен бик киң итеп ачачак...

Хәер, безнең закон өч тел белү мәсьәләсен күтәреп чыккач, бер мескен татарның сүзе тарихтагы, кайчандыр булган бер хатирә кебек кенә кала бирә. Иң мөһиме, ул хатирәңне башка милләт кешеләре генә түгел, ә татарлар үзләре дә бик тырышып онытырга омтыла. Таныш татар теле укытучысы әйтмешли: «Баламны татар сыйныфына биреп, ни мәгънә? Беренче сыйныфтан ук рус сыйныфында укысын, тормышта да югалмас, ЕГЭны да яхшы бирер, ә татар телен ул өйдә дә өйрәнә ала». Өйдә өйрәнмичә, кая барсын: әби белән бабайның кайберләре бер генә авыз да русча сүз белми бит...

Әмма ни генә әйтсәк тә, бу телләрсез яңа технологияләр белән эшләп булмас шул. Шуңа күрә телгә дә, технологияләргә дә бер генә сүз: әйдә, дускай, рәхим ит!



# Саннарда - язмышлар

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Һәр Яңа ел яңа сан белән килә. Аңа кергә торган айлар һәм көннәр шулай ук, Галәм әйләнешенә карап, циклларга бүленә. Һәр кешенең, үз чиратында, шәхси циклы бар. Ел, ай, көн цикллары исемнең мәгънәсе һәм башка факторлар кеше язмышына, тормышына көчле тәэсир ясый.

Яңа 2012 елда берничә сан бик актуаль булачак икән. Беренчедән, биш саны. Ул – Юпитер планетасына туры килә торган сан (киләсе ел саннарының суммасы – 2 + 0 + 1 +2 = 5). Икенчедән, ике саны – Ай белән бәйләнгән (елның беренче цифрасы). Һәм, өченчедән, унике саны – Кучкарга туры килә. Уникенең тагын бер ягы – ул бер (Кояш) һәм ике (Ай), ә аларның суммасы – өч (Марс). Шулай итеп, без ел буе менә шундый төрле-төрле саннар компаниясендә яшәячәкбез, диләр нумерологлар.

Иң төп сан – биш. Ул Юпитерга карый. Йолдызларның патшасы булган бу планета кешенең акыл үсешенә, дини традицияләренең ныгуына да бәйле. Юпитер елында мораль принциплардан чыгарга ярамый, дип кисәтә нумерологлар.

Гомумән, нумерология ярдәмендә кешенең элек яшәгән тормышы турында да һәм киләчәк язмышын да белергә мөмкин, диләр алар. Нумерология бик күптәннән, безнең эрага кадәр барлыкка килгән. Саннарның кеше тормышына тәэсире бик зур булуга күпләр ышанмый, ә кайберәүләр, киресенчә. Чәчәк бәйләмендәге җөп саннар иясенә күңелсезлекләр алып килә, дип ышанулар модага кергән. Белгәнебезчә, 13 саны да бик үзенчәлекле. Кайбер илләрдә биек йортларның унөченче каты әйтелми. Самолет һәм поездларның бу номер билгеләре юк.



# «Яңа ел» салаты

***Ингредиентлар:***



*Тавык филесы – 300 гр.*
*Сыр – 100 гр.*
*Йомырка – 5 данә.*
*Кара җимеш – 150 гр.*
*Әстерхан чикләвеге – 100 гр.*
*Майонез, тоз.*

***Ясау ысулы:***

*Филены пешерергә, суытырга һәм турарга. Сыр, йомырканы кыргыч аша чыгарырга (йомырканың агын һәм сарысын аерырга). Кара җимешне кайнар суда яхшылап юарга һәм вак итеп турарга. Чикләвекләрне вакларга. Савыт төбенә филены, аннары йомырка сарысын, кара җимеш, сыр һәм чикләвекләрне катламлап салырга. Һәр катлам саен тоз сибеп, майонез сөртергә. Салатны «Кар бабай» кебек ясарга, өстен йомырка агы белән бизәргә. Борынын кишер, күзләрен кара борыч белән ясарга. Бу салат бәйрәм өстәленә тагын бер ямь өстәп торыр. Ашларыгыз тәмле булсын!*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999
Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева, Э.Р.Ибраһимова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru Сайт: ksu.ru
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла